ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.01.2023 Олы Кайбыч ав. № 10

Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 13 сентябрендәге 987 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Хезмәткәрләр өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары) билгеләргә.

2. «Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнелә торган Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 12 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.01.2023_____ 10__ номерлы
Карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренә түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тарифлы ставкалар (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,00 | 15 279 |
| 2 | 1,0159 | 15 522 |
| 3 | 1,0323 | 15 773 |
| 4 | 1,0480 | 16 012 |
| 5 | 1,0656 | 16 281 |
| 6 | 1,0827 | 16 543 |
| 7 | 1,1010 | 16 822 |
| 8 | 1,1187 | 17 093 |
| 9 | 1,1363 | 17 362 |
| 10 | 1,1553 | 17 652 |
| 11 | 1,1736 | 17 931 |
| 12 | 1,1933 | 18 232 |
| 13 | 1,2129 | 18 532 |
| 14 | 1,2325 | 18 831 |
| 15 | 1,2528 | 19 142 |
| 16 | 1,2738 | 19 462 |
| 17 | 1,2947 | 19 782 |
| 18 | 1,3163 | 20 112 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.